

**И туган тел, и матур тел,**
**Әткәм-әнкәмнең теле!**
**Дөньяда күп нәрсә белдем**
**Син туган тел аркылы –**
**дип башлыйм әле сүзләремне.**

**Табышмакларның җавапларын әйт.**

**Боз һәм кар эреде, сулар йөгерде,**
**Елап елгалар, яшьләр түгелде.**
**Көннәр озая, төннәр кыскара –**
**Бу кайсы вакыт, я, әйтеп кара?! (Балалар җавап бирәләр: “ЯЗ”)**



**Ашлыклар үсте, башаклар пеште,**
**Кояш пешерә, тиргә төшерә.**
**Халык ашыга, китә басуга,**
**Урагын ура. Бу кайчан була? (Балалар җавап бирәләр: жәй")**



**Кырлар буш кала,**
**Яңгырлар ява.**
**Җирләр дымлана,**
**Бу кайчан була? (Балалар җавап бирәләр: “КӨЗ”)**



**Һәр җир карланган,**
**Сулар бозланган.**
**Уйный җил, буран.**
**Бу кайчан, туган? (Балалар җавап бирәләр: “КЫШ”)**



**Нәкъ кеше кебек үзе,**
**Маңгаенда мөгезе.**
**«Былтыр кысты», – дип кычкыра.**
**(«Шүрәле»).**



**Чуар, йомшак күлмәге,**
**Тотсаң, уңа бизәге.**
**Тоттырмый, китә очып,**
**Я кала җирдә посып. (Күбәләк – «Бала белән**



**Теле чибәрнең- <u>үзе чибәр.</u>**
**Тәмле тел- дару, ачы тел- <u>агу.</u>**
**Тел күрке- <u>сүз.</u>**
**Яхшы сүз чәкчәк, яман сүз- <u>чәнечке.</u>**




JulianaN



# Туган тел

**И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!**
**Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.**
**Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,**
**Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.**